## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Кәшер авыл җирлегенең Иске Кәшер авылы торак пунктында**
**2025 елда үзара салым кертү турында**

**2024 елның 15нче ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Иске Кәшер авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авылы Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; көндезге бүлек студентлары; хәрби хезмәт һәм контракт буенча үтүче гражданнар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш , яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);
2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть);
3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; ( вак таш сатып алу, юлларны грейдировкалау ,МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);
4) халыкның күпләп ял итү урыннарын( парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (территорияләрне чабу,хезмэткэ түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)
5) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары алу)

3. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Н. Дәүләтҗанов